

Рәшит БӘШӘР

# *Ашыгылды, мин гел ашыктым...*

*Рәшит Бәшәр (Рәшит Гаффар улы Бәшәров) 1949 елның 7 октябрендә Кукмара районы Янил авылында туган. Шагыйрь, прозаик, балалар язучысы, Абдулла Алиш һәм Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши. Күренекле каләмдәшебез, журналыбыз аксакалы бу айда 70 яшьлек гомер бәйрәмен каршылый. Аны редакциябез коллективы исеменнән ихлас котлыйбыз. Нык сәламәтлек, тән һәм җан сихәтлеге, сүрелмәс иҗат дәрте телибез.*

## Автобиография

Әни – кулсыз. Ялгыз интегә.
Яше тама яран гөленә.
«Таянырлык ирен булсачы!» –
Колагымда чыңлый әле дә.
Сугыш җиле һәрбер капканың
Күгәннәрен кат-кат каерган.
Әни. МТС. Пилорама
Уң кулыннан аны аерган.
Ашы кайный. Сөйли әнием:
«Гариплә́ндем шулай мин, улым...»
Кузаллыйм мин пычкы чүбендә
Сикергәләп яткан уң кулын.
Тәмле исләр. Әни аш бүлә.
Нindидер җыр суза кинәттән.
Җанындагы бөтен хәсрәте
Ташып чыга моңсу йөрәктән.
Мин тук. Кычытканлы яшел аш
Хәлсез беләгемә көч кертте.
Капка ачык. Чыктым урамга.
Тән ялангач. Койма буенда
Ата казлар талап кычкыртты.
Мин алардан качып өлгердем.
Ата казлар калды ысылдап...
Уйнак тайдай җитез йөгердем.
Малайчактан үсмерчакның мин
Кызыл алмасына үрелдем.
Кызыл алма тоткан яшь егет –
Ул хыялый егет мин идем.
Ашыгылды, мин гел ашыктым.
Инде менә коңгырт күзле бер
Чибәренә җирнең гашыйкмын.
Йолдыз санап таңнар аттырам,
Якты кояш булып яктырам.
...Мин яшь белгеч. Университет
Яннарыннан үттем юл буйлап.
Мәрмәр күзле япь-яшь Ульянов
Озатып калды мине кул болгап.
Бар мөлкәтем: зәңгәр дипломым,
Бер мендәрем, ике кашыгым.

Янәшәмдә хатын теркелди,
Улы елый мин яшь гашыйкның.
Бишек җырын хатын көйләде,
Кашык ияләре күбәйде.
Үстеләр... Күрдем: аулакта
Бер чибәрне улым үбәйде.
Өйләнде дә, туды бәләкәч –
Татлы хакыйкате яшәүнең.
Һәм кызым да булды оялы –
Оныклары чаба Бәшәрнең.
...Шигырь язам. Кайбер бәндәләр,
Юләр бу дип, көлеп узадыр.
Шагыйрь – дәрвиш ул. Ә дәрвишләр
Әкрен генә эчтән сызадыр.
Янып бетә бәгырь. Сүнә шәм.
Каләм төшә кулдан... галәмгә.
Һәм галәмдә калган шигырьләр
Бер юаныч була адәмгә.
...Картлык тора ишек катында,
Бик телләшми инде хатын да.
Кайчагында ярты көн буе
Авызга су кабып йөрисең.
Үпкә бетә... Һәм бүлмәндәге
Гөлләреңә суны бөркисең.
Төште дисәм хатын башымнан,
Башка инде картлык атланды.
Берәм-берәм шаян оныклар
Сыйпаштырып китә сакалны.
«Иртә киттем бугай яшьлектән,
Нигә диеп болай ашыктым?»
Шулай дим дә... Ах, мин карт бүре
Сабыр картлыгыма гашыйкмын.
Яшь кызларга күзем төшкәли,
Яннарыннан бик еш үткәлим.
Ара-тирә, мәзәк сүз сөйләп,
Чәчләреннән сыйпап киткәлим.
Елмаймыйча яшәп үтелгән
Һәрбер кичем, һәрбер көн әрәм.
...Рәнҗетмәгез,
Сабый чагымдагы
Ата казымны мин, малайлар,
Сәлам итеп сезгә җибәрәм.

## Әдәби кичәдән соң

Елмаеп килдең дә син:
– Исәнмесез! – дип дәштең.
«Шагыйрәдер бу ханым...» –
Шагыйрәгә бик, бик тә
Охшаш иде рәвешең.
– Шигырьләр язасызмы?
– Мин, абый, шагыйрь түгел,
Бер хыялый җан булам.
Көндез көләч, төннәрен
Төнбоектай йомылам.
Рәмзия мин... Рәмзия...
Унынчыга күчкән чак...
Авылга сез җәй көне
Төзелешкә килдегез.
Бигрәк чая студентлар,
Бигрәк шаян идегез.
– Рәмзияме? Синме бу?
Агыйделдән үземе?
Искә төшермәк булам
Онытылган йөзеңне.
Күзләреңә бактым мин,
Тирән алар, яп-якты,
Мондый күзләр бик сирәк.
...Романтик яшьлеккә
Әйләнеп кайтты йөрәк.
Хәтерлим...
Күрәм сине
Яңгыр юган болында.
Ялгыз чуар күбәләк
Җилпенә уң кулында.
Кап-кара чәчләреңә
Чәчәк тажы элнгән...
Сиңа карыйм, аппагым,
Үткән аша бүгеннән.
Элеккечә чибәр син,
Үзгәргәнсең дә инде.
Маңгаеңдагы сырлар
Күбәеп киткән, димме?
Бик гүзәл син, мөлаем,
Бик горур син, сабыр син.

Моң тулы күзләремдә,
И Алиһә, синең сын.
Яшьлек болының белән
Йөрәгемә сыйгансың...
Хуш, чибәркәй, исән бул,
Кайтып килдем үткәнгә.
Искә алырсың мине
Кичке җилләр үпкәндә.

## Ак болытлар астында

Урманчы кайтты аудан...
Күлмәк җиңе ертылган,
Яшь хатын тегәр инде,
Чишмә суында чайкап
Кибәргә эләр инде.
Ашы да кайнап чыкты,
Шулпаны бүләр инде.
– Иренеңне пешермә,
Бик кайнар! – дияр инде.
Аннан алар икәүләп
Аланга килер инде.
Гашыйклар үбешкәнне
Былбыл кош күрер инде.
Яшь юкә дә кызарып
Оялып торыр инде.
Битенә яфрак каплап,
Читкә борылыр инде.
Хатын ирне чеметер,
Чыркылдап көләр инде,
Ир хатынга су сибәр,
Яшьлек бит юләр инде.
Аяк астында үлән
Ямь-яшел челтәр инде.
Черки тешләр, яшь хатын
Кулларын селтәр инде.
Ары китәр йөгереп,
Ир аны куар инде.
Ике йөрәк, бер булып,
Үләнгә авар инде.
Килеп эленер гөлгә:
– Аһ! – дигән дәртле аваз...
Ап-ак болытлар йөзәр.
Кош сайрар. Күкләр аяз.
Урман өстенә галәм
Эңгерен эләр инде.
Гашыйкларга барча кош
Тыныч төн теләр инде.

## Озын юл

Инде ничә гасырлар
Санадылар. Саныйлар.
«Ничек үрчи бу кавем?» –
Сынадылар. Сыныйлар.
...Далада кала корды
Атлы, арбалы татар.
Илгә баш булып торды
Алтын Урдалы татар.
Мәңгелек түгел бер ни,
Таралды... Тараттылар.
«Нәселе бетсен, корсын!» –
Өзлексез каралттылар.
Каралткан саен татар
Агара гына торды,
Кулына ипи тотып,
Гел алга бара торды.
Өй түбәсе ябулы,
Ак мунчасы ягулы,
Бәлеше пешә мичтә.
Татарча көйли чишмә
Йолдызлы якты кичтә.
...Инде ничә гасырлар
Саныйлар, санасыннар,
Сыныйлар, сынасыннар.
Саналып һәм сыналып,
Киләчәгенә татар
Атлый бик сабыр гына.
Ил тоткан ханнар каны
Сулкылдый тамырында.
Ышана ул югалткан
Дәүләтен табарына.
Ак юллар татарыма!

## Тынлык

Кояш кунган камылга
Сары яфрак ябышкан
Тымызык җил кагыла.
Чәчелеп китә нурлар...
Сулап ята үз җаена
Шәп-шәрә калган кырлар.
Илдән китәр мәлендә
Кара карга көтүләре
Салам кибәннәрендә.
Сары басу түрендә
Олы юлга чыгучы бер
Ялгыз юлчы күренә.
Бик моңсу чаклар инде...
Пыскый-пыскый әкрен генә
Сүнә учаклар инде.

## Туган яктан искән җилләр

Бер җыр килә туган ягымнан –
Болыннарда җиләк пешәдер.
Яшь-яшь кызлар таңгы сукмактан
Уйчан болыннарга төшәдер,
Карашлары гөлгә төшәдер.
Бер җыр килә туган ягымнан –
Авыл өсләп болыт агадыр.
Һаваларда очкан кошларның
Сулышына җилләр кабадыр,
Сулышына җилләр кабадыр.
Бер җыр килә туган ягымнан –
Тау биленнән чишмә тибәдер.
Чәчләремнән сыйпый җылы җил,
Туган яктан искән җилләрдер –
Мине сагнып искән җилләрдер.

## Балачакның бер көне

Әни мичне агарта,
Мин рәсем буйыйм:
«Туган көнеңә, әни,
Өлгертеп куйыйм!»
Чыгып чабам урамга:
«Аз гына уйныйм...»
Балачак һавасы татлы,
Һич сулап туймыйм.
Уенчак бер тай сыман мин –
Урамга сыймыйм.
Учымда – песи борчагы,
Дустымны сыйлыйм.
Үрмәлим агач башына –
Үземне сыныйм.
Күккә үк менеп җиткәнмен,
Инде ни кылыйм?
Биектән туган илемне
Бер күреп калыйм.
Бормалы юлны күзәтәм,
Хәтта тын алмыйм.
Әнә бер кыз... Хыялымда
Җитәкләп атлыйм.
«Исемең ничек? Әйт инде!» –
Кат-кат кабатлыйм.
Агачтан шуып төшкәч тә,
Шул кызны уйлыйм.
«Күрше авыл кызы микән?» –
Һич уйлап туймыйм.
...Гомеремнең бер көнен дә
Хәтердән җуймыйм.
Аргамаклы тугайларга
Оча ак уем.
Теләсәм дә, шул чакларны
Кайтара алмыйм.
Шул илгә кайтып килергә
Җай таба алмыйм.